ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2025 ел, 17 октябрь №4/3

Җирлекнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының тәкъдимен кабул итәргә:

-җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелүче хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү буенча төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле контроль органның вәкаләтләрен һәм функцияләрен.

2.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында һәм бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр авыл җирлегенең бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын карауга тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлеге Башлык урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
“Шәһәр тибындагы Апас бистәсе”
муниципаль берәмлеге
башлыгы-
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Апас шәһәр җирлеге Советы
рәисе
А.Г. Җиһаншин